РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БОЛЬШЕШЕМЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ШӘМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 56-6-48, факс 56-6-48

# КАРАР

**8 ноябрь 2019 ел** **№ 2**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Шәмәк торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Олы Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсенә нигезләнеп **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 21 ноябрендә 11.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш районы Кече Шәмәк авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Шәмәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Шәмәк пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым

кертүгә һәм  аннан алынган акчаларны   җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез  риза буласызмы:

- Кече Шәмәк авылындагы Партизан ур., Совет ур., Җиңүнең 40 еллыгы урамнарын төзекләндерү;

- Кече Шәмәк авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәк авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Шәмәк авыл җирлеге башлыгы** **А.И. Афанасьев**